ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 август 2018 ел № 4724

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать
тәртибен саклау турында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү максатында, «Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүнең бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 нче карарына таянып

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда җәмәгать тәртибен саклауны оештыру тәртибен, кушымтада каралганча расларга.

2. Яр Чаллы шәһәре территориясендә табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда шәһәрнең авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне башкарганда катнашучы барлык хезмәтләре, оешмаларының гамәлләренә җитәкчелек итүне һәм координацияләүне Яр Чаллы шәһәре территориясендә табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү һәм Яр Чаллы шәһәренең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясенә йөкләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 24 августындагы
4724 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда җәмәгать тәртибен саклауны оештыру
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Яр Чаллы шәһәре территориясендә табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәте иминлеген, пропуск режимын, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауны тәэмин итүнең максатларын, бурычларын, тәртибен билгели.

2. Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау Яр Чаллы шәһәрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүнең территориаль ярдәмче системасының шәһәр звеносы эшчәнлеге кысаларында гамәлгә ашырыла.

3. Җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәте иминлеген, пропуск режимын, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауны тәэмин итү буенча бурычларны үтәү, шулай ук гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда халык арасындагы паниканы кисәтү һәм булдырмау өчен Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы идарәсе, Яр Чаллы шәһәре буенча ведомствоара сак бүлеге – «Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренең ведомствоара идарәсе» ФГКУ филиалы һәм Башкарма комитетның җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсенең көчләре һәм средстволары җәлеп ителә.

4. Гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләгәндә эчке эшләр, ведомствоара сак органнарының көчләре һәм средстволары законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән аларга йөкләнгән бурычлар нигезендә кулланыла.

5. Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауның төп бурычларына түбәндәгеләр керә:

1) Яр Чаллы шәһәре территориясендә килеп чыккан аварияләр һәм гадәттән тыш хәлләр турында көчле тавышлы элемтә белән җиһазландырылган транспорт чараларын файдаланып, халыкка хәбәр җиткерү;

2) хәлнең торышын бәяләү, җәмәгать тәртибен, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау, пропуск режимын оештыру буенча бурычларны үтәүне тәэмин итү өчен кирәкле сандагы көчләрне һәм средстволарны билгеләү;

3) гадәттән тыш хәлләр зонасына керү режимын гамәлгә ашыру;

4) зыян күргән затларны гадәттән тыш хәл урыныннан алып чыгу өчен җәмәгать һәм шәхси транспортны җәлеп итү;

5) транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен җайга салу;

6) паника һәм массакүләм тәртипсезлекләрне булдырмый калу;

7) халыкны куркыныч зона, бина, корылмалардан эвакуацияләүне тәэмин итү;

8) коткару һәм авария-техник көчләренең һәм чараларның авария, һәлакәт урыннарына тоткарлыксыз хәрәкәт итүләрен тәэмин итү;

9) җәмәгать тәртибен, матди кыйммәтләрне урлау очракларына юл куймауны тәэмин итү;

10) куелган бурычларны үтәүгә үз вакытында карар кабул итү өчен хәлләрнең үсешен прогнозлау.

6. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы идарәсенең бүлекчәләре, хезмәтләре һәм хәрби тәртип төркемнәре, Яр Чаллы шәһәре буенча ведомствоара сак бүлеге – «Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренең ведомствоара идарәсе» ФГКУ филиалы һәм Башкарма комитетның җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсенең гамәлләрен идарә итү һәм координацияләүне тәэмин итү һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүнең территориаль ярдәмче системасының шәһәр звеносы идарәсе органнары белән үзара берлектә гамәлгә ашыру максатында җәмәгать тәртибен саклау буенча оператив штаб төзелә.

7. Җәмәгать тәртибен саклау буенча оператив штаб гадәттән тыш хәлләр зонасында булган халык һәм оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле, гадәттән тыш хәлләр зонасында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча карарлар эшли.

8. Гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләүгә җәлеп ителгән барлык көчләр һәм чаралар белән идарә итүгә, алар арасында үзара эшчәнлекне оештыруга, шул исәптән җәмәгать тәртибен саклау буенча җитәкчелек итүне гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү җитәкчесе гамәлгә ашыра.

9. Гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү җитәкчесе Яр Чаллы шәһәрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия рәисе боерыгы белән билгеләнә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ